# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“23” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 21 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта, 2019 елның 23 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Күшәр авылы территориясендәге Ашыт елгасы чокырыннан су агызу өчен канауны тирәнәйтү;
   - Күшәр авылы көтүлегендә, елга аша маллар чыгу өчен куперчек төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 478 (дүрт өч җитмеш сигез ) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 292 (ике йөз туксан ике) кеше, бу 61,08 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 292 (ике йөз туксан ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2020 елда Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

   Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Күшәр авылы территориясендәге Ашыт елгасы чокырыннан су агызу өчен канауны тирәнәйтү;
   - Күшәр авылы көтүлегендә, елга аша маллар чыгу өчен куперчек төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу.” мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.
3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Гарипова Г.Х..